**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР — ПОСТАНОВЛЕНИЕ

от 23.06.2020 — № ПР-128

Башкарма комитет җитәкчесенең «Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2018 елның 5 апрелендәге ПР-65 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» гы Федераль законны үтәү йөзеннән, бюджет һәм бюджеттан тыш акчаларны нәтиҗәле файдалану, намуслы көндәшлекне үстерү, кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштырганда ачыклык һәм үтә күренмәлелекне тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар җибәрүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында " 2018 елның 5 апрелендәге ПР-65 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 сентябрендәге ПР-187 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче — И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
23.06.2020 № ПР-128

1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар җибәрүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шакирова Алия Миндыгали кызы | комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлеге начальнигы |
| Митрофанова Айгөл Рифкат кызы | комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлегенең баш белгече |
| Әхмәева Илзирә Фәндүс кызы | комиссии секретаре, әйдәп баручы белгеч |
| Члены комиссии: | |
| Гарипов Руслан Илус улы | Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| Салимов Дильфат Зөлфәт улы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы |
| Мирзашарипова Ойгуль Миннефарит кызы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы |
| Абударов Фәндус Индусулы | "УКС" МУП директоры |